ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.02.2023 Баулы шәһәре №51

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 119 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 119 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6. пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү каралмаган.»;

2 нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.1. пунктының 4), 6) һәм 8) пунктчалары үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.6.1. пунктының 2) һәм 4) пунктчалары үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.8.2. пунктының 6) пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. 2.5.1. һәм 2.6.1 пунктлар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров